Мөслим гимназиясе укучылары газетасы

# ТЫЛСЫМ+

Бишенче сан

Гыйнвар, 2015 нче ел

## Бу санда:

*Гимназия сулышы* 1

*Дуслык турында сөйләшик* 2

*Могҗизалы өчлек* 3

*Буш вакы-тың бушка үтмәсен* 4

## Гимназия бүген



БЕЗНЕҢ ГИМНАЗИЯ БУЛ – Татарстан Республикасының электрон белем бирү компетенция үзәге.

БЕЗНЕҢ ГИМНАЗИЯ БУЛ – Россия “Милли мәгариф” проекты җиңүчесе – 2008.

БЕЗНЕҢ ГИМНАЗИЯ БУЛ – “Укучыларның туклануын оештыру буенча иң яхшы мәктәп ашханәсе” VI Республика конкурсы җиңүчесе - 2009.

БЕЗНЕҢ ГИМНАЗИЯ БУЛ – медицина кабинетларының Республика смотр-конкурсы җиңүчесе - 2014.

БЕЗНЕҢ ГИМНАЗИЯ БУЛ – “Сәламәтлек саклау юнәлешендә “Алтын дәрәҗә”ле мәктәп” квалификацион характеристикасына ия булган уку йорты - 2014.

БЕЗНЕҢ ГИМНАЗИЯ БУЛ – 405 укучы, 46 укытучы бердәм эшләүче коллектив.

## ГИМНАЗИЯ СУЛЫШЫ

### 2015 нче ел - Россиядә Әдәбият елы



Матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр федераль агентлыгы җитәкчесе Михаил Сеславинский белдергәнчә, агымдагы елда әдәбиятка багышланган зур күләмле чаралар, шул исәптән “Әдәби Евразия” дә үткәреләчәк. Мондый чаралар арасында “Россиянең әдәби картасы”, “Библиотөн - 2015”, “Хастаханәләрдә китаплар”, “Китап белән җәй”, “Бөтендөнья китаплары көне” проектлары, “Россиянең әдәби башкаласы” конкурсы оештырлачак.



### 2015 нче ел - Татарстанда Парклар һәм скверлар елы

Парклар һәм скверлар елы территорияләрне комплекслы үстерү, төзекләндерү һәм яшелләндерү мәсьәләләренә җәмәгатьчелек игътибарын җәлеп итү максатыныннан чыгып игълан ителгән.

Мөслимдәге паркларны тәртиптә тотуда үз өлешебезне кертик.

### Фән офыклары

Гимназия укучылары арасында “Фән офыклары” проектлар бәйгесе бара. Чираттагы утырышлар 27-28 гыйнварда була. Син кайсы фәнгә сәләтле? Нинди ачышларың бар? Башкалар алдында чыгыш ясап, үзеңнең проектыңны яклый аласың. Әйдә, кыюрак бул! Син дә кушыл!

### Рекордлар китабы

Мөслим гимназиясенең “Рекордлар китабы”на керәсегез киләме? Бу бик гади. Аның өчен үзеңнең башкалардан үзгә булган гамәлең турында гариза бирергә генә кирәк. Әйдәгез, гимназия елъязмасында сезнең дә эзегез калсын! Тулы мәгълүматны гимназия сайтыннан табарга мөмкин.

### Рәсәй эрудитлары

Гимназия укучылары «Рәсәй эрудитлары - 2015» конкурсында матур нәтиҗәләргә ирештеләр. 9 нчы б сыйныфы укучысы Галиев Гадел информатика фәне буенча икенче урынга лаек булды. Башка фәннәр буенча 35 укучы лауреат булдылар. Куратор - башлангыч сыйныфлар укытучысы Гумерова А.Р. Афәрин! Алдагы конкурсларда уңышлар телибез!




### Матбугат битләрендә

«Әдәбият елы» кысаларында гимназиянең татар теле һәм әдәбияты укытучысы Тимергалиева Э.В.ның «Казан утлары» журналында «Фән» бүлегендә «Фоат Садриевның «Таң җиле» романында борынгы әдәбияттан килгән традицияләр» исемле мәкаләсе басылды.

Язма белән http://kazanutlary.ru сайтыннан танышырга мөмкин.

## ДУСЛЫК ТУРЫНДА СӨЙЛӘШИК



***Дуслык төшенчәсен төрле кеше төрлечә аңлый.*** Дуслар булса, бу дөньяда яшәве дә җиңелрәк. Бүгенге көндә виртуаль дөньяда яшәүче дуслар күбәйде. Күзгә-күз карап аралашу, хисләр уртаклашу, ихлас күңелдән сөйләшеп утырулар юк. Чын дус нинди була? Виртуаль дуслык тере аралашуны алмаштыра аламы? Мәктәп елларындагы дуслык гомерлекме? Әйдәгез, үзебезнең гимназия укытучыларыннан, укучыларыннан шул турыда сорап карыйк.

***Сорау: Сезнеңчә, чын дус нинди булырга тиеш? Дуслар белән виртуаль дөньяда аралашу җитәме?***

***Ямалова Гөлнара Фердинат кызы, социаль педагог:*** Чын дуслык ул - авыр чакта таянырлык дустың булу. Аңа серләрең сыя, син нинди булсаң, ул сине шундый итеп кабул итә. Чын дуслар күп булмый, бәлки гомер буена берәү генәдер? Социаль челтәрләрнең аралашу өчен өстенлекле яклары бар, әлбәттә. Бүгенге тынгысыз заманда анысы да бик ярап куя. Шулай да, якыннан аралашуга берни дә җитми!

***Мухаметдинова Римма Равил кызы, тарих укытучысы:*** Дус - кайгы килгән чакта ярдәм кулын сузучы, шатлык-сөенечләреңне уртаклашучы. Минемчә, дуслары булган кеше генә бәхетле була ала. Андый кеше беркайчан да югалып калмый. Чын дуслыкны тоя белергә, югалтмаска кирәк. Яшьлектәге дусларыбыз хәзер инде безнең гаилә дусларыбыз, бик еш очрашып, аралашып яшибез.

***Мортазина Ләйсән Габбас кызы, башлангыч сыйныфлар укытучысы:*** Чын дус - сиңа авыр вакытта ярдәм итәргә әзер кеше. Ул синең өчен утка да, суга да төшәргә әзер, минемчә. ВКда, “Мой мир”, “Одноклассники” да дусларым белән аралашам. Минем җанлы аралашуга да вакытым кала: өебездә кунаклар кабул итәргә, рәхәтләнеп сөйләшергә яратам.

***Солтанова Ландыш Фазыл кызы, технология укытучысы:*** Минемчә, кешенең дусты ун-унбиш була алмый. Дус ул ике-өч кенә була. Дус кеше сиңа таяныч, кайгыда да, шатлыкта да синең белән баручы.

***Сорау: Сезнең мәктәп елларыннан ук аралаша торган дустыгыз бармы?***

***Мәрданшина Рушания Мөхтәр кызы, география укытучысы:*** Мәктәп елларындагы дустым белән хәзер дә дус. Тик сирәк аралашабыз, чөнки ул башка шәһәрдә яши. Шулай да интернет аша хәбәрләшеп, телефон аша сөйләшеп хәл белешәбез. Төрле уку йортларында укыган чорларда һәрвакыт бер якын дустым булды. Хәзер иң якын дусларым - ике кызым һәм бергә эшләгән коллегаларым.

***Фәрхетдинова Ләйсән Әхмәтгаян кызы, башлангыч сыйныфлар укытучысы:*** Мәктәптә укыганда сыйныфташым белән бик дус идем. Дуслык хисләре мәхәббәткә әверелде. Бүгенге көндә классташ дустым - гомерлек тормыш юлдашым. Гаиләбездә ике кызыбыз үсеп килә. Мәктәп елларындагы дуслыкның шундый матур дәвамы да була икән...

***Идиатуллина Маргарита Александр кызы, башлангыч сыйныфлар укытучысы:*** Яшел чирәмдә бергә уйнап үскән дустым белән хәзер дә дуслыкны дәвам итәбез. Ул Чаллы шәһәрендә балалар табибәсе булып эшли. Оныкларым авырганда, аның зур ярдәмен тоям. 20 декабрьдә аның туган көненә бардым. Шулай туган көннәргә, туйларга бергәләшеп йөрибез, бер-беребезгә ярдәм итәбез. Тугрылыклы, ярдәмчел. Шундый балалык дустым бар минем. Мин үзем, виртуаль аралашуга караганда, очрашып сөйләшү – үзе бер гомер, дияр идем. Дусларыгызны сайлый белегез, чын дус тапкансыз икән, аның кадерен белегез, элемтәләрегезне саклагыз!

***Шәмсетдинова Гүзәл, 7 нче б сыйныфы укучысы:*** Кеше дуслыгы көчле була. Якын дуслар һәрвакыт бер-берсен аңлыйлар, сөенечләрен бергә бүлешәләр, кайгыларны аңлап ярдәм итәләр. Чын дуслык беркайчан да сатылмый. Минем дә якын дустым бар. Без аның белән бер мәктәптә, бер сыйныфта укыйбыз. Мин аңа нинди генә сорау белән мөрәҗәгать итсәм дә, ул мине кире какмас. Ул миңа һәрвакыт булышырга әзер. Без бер-беребездән башка тора алмыйбыз. Мин үземнең шундый дустым булуына бик шатмын. Чыннан да, чын дустың булу - үзе зур бәхет. Тугры дустың бар икән, синең таянычың, киңәшчең бар дигән сүз. Зур байлыкка ия булып та, чын дустың булмаса, яшәве дә рәхәт түгел, дөньяның яме булмас иде. Чын дустың булса, бернәрсә дә авыр түгел. Мин чын дуслык төшенчәсен шулай аңлыйм.

*(ВКдагы калган дусларым үпкәләмәсен, мин аларны да яратам, хөрмәт итәм)*

***Мәгъданова Ләйсән, 7 нче б сыйныфы укучысы***

## МОГҖИЗАЛЫ ӨЧЛЕК

### Таныш булыгыз: «Ел укытучысы - 2015» конкурсының муниципаль этабы финалистлары



**Югары категорияле рус теле һәм әдәбияты укытучысы Арсланова Лариса Николаевна - ТРның “Иң яхшы укытучы” Гранты иясе.**

***Лариса Николаевна, сез район тарихында 100 баллга БРИ тапшыручы укучы әзерләгән бердәнбер укытучы. Татар мохитендә тәрбияләнеп үскән балаларны бөек Пушкин, Лермонтов теленә өйрәтү авырмы?***

Әлбәттә, бу - бик тә үзенчәлекле, катлаулы процесс. Телне тоемлау балада бик иртә формалаша. Кайсы телне өйрәтсәк тә, аны ана теленә таянып оештыру отышлы санала. Рус теленә өйрәтүнең бик күп факторларын санап китәргә мөмкин булыр иде. Баланың гомуми үсеше, акыл дәрәҗәсе, хәтере, тел күренешләрен аңлый белүе, аралашу культурасы – болар барысы да исәпкә алынырга тиеш дип саныйм.

***БДИ га өйрәткәндә нинди ысулларны отышлы дип санайсыз?***

Укучыны БДИ га әзерләгәндә, беренче чиратта, баланы психологик яктан әзерләргә, аның үзендә ышаныч тудырырга кирәк. Ә аерым ысулларга килгәндә, мин гап-гади методика белән эшлим, аның нигезендә фикерләү алгоритмы ята.

***Кайсы шагыйрьләрне яратып укыйсыз?***

Китап уку кечкенәдән үк иң яраткан шөгылем булды. Әнидән качып китап укый идем. Танылган рус әдибе Евгений Евтушенко иҗатына гашыйкмын. Аны яттан сөйлим, цитаталарын кулланам.

***Кумирларыгыз бармы?*** Мәктәп елларындагы рус теле һәм әдәбияты укытучым Ханова Фәния Зариповна – минем маягым.

***Тормыш девизыгыз?*** “Кто постигает новое, лелея старое, тот может быть учителем”. *Конфуций.*



**Югары категорияле биология укытучысы Бариева Ләйсән Фәһәметдин кызы - ТРның “Иң яхшы укытучы” Гранты иясе.**

***Ләйсән Фәһимовна, ни өчен сез биология укытучысы һөнәрен сайладыгыз? Ул сезгә ошыймы?***

Мәктәптә укыганда табиб булырга хыялландым. 1998 елда мәктәпне гел “бишле” билгеләренә генә бетердем. Медальга ия булдым. Ул еллар бик болгавыр иде. Медицина институтына керә алмам дигән шик туды. Алабуга институтында укырга кердем. Хәзер шушы һөнәрне сайлавыма үкенмим. Балалар белән эшләргә яратам.

**Сезнең укучыларыгыз олимпиадаларда күп урыннар алганнар. Аларны әзерләү бик күп көч таләп итәдер?**

Әйе, соңгы биш ел эчендә минем укучылар арасында 25 тән артык олимпиадаларның муниципаль турында җиңүчеләр, призёрлар булды. Дөрес, Айгөл, укучыларны олимпиадага әзерләү бик күп көч таләп итә. Ул бер ел эчендә генә башкарыла торган эш түгел.

**Укытучы хезмәте бик авыр, җаваплы хезмәт. Олимпиадалар, конкурслар, сыйныф белән җитәкчелек итү, сәләтле балалар белән, ата-аналар белән эш... Сез ничек җитешәсез?**

Кеше үзенең вакытын дөрес бүлә белергә тиеш. Үзеңә максат куйсаң, иренмәсәң, бар эшкә дә җитешергә була.

**Сез укыткан балалар арасында сезнең һөнәрне сайлаучылар бармы?**

Минем укучылар арасында медицина юлын сайлаган укучылар, биология укытучысы булырга теләгән һәм шул институтларда укыган балалар да бар.



**Югары категорияле физика укытучысы Сәяхова Зөлфирә Мөхәр кызы, ТРның “Иң яхшы укытучы” Гранты иясе.**

***Физика фәне дигәч, нишләптер ир-ат укытучы күз алдына килә. “Не женская эта наука” дияр идем мин... Сезнең фикерегез ничек?***

“Не женская эта наука,” - дип инде... Валентина Терешкова бу сорауга җавап эзләп тормаган ләбаса, Галәм киңлекләрен өйрәнергә космоска кадәр очкан! *(көлә)*

***Соңгы елларда шактый күп укучы физикадан БДИ сайлый. Бу нәрсә белән бәйле дип уйлыйсыз? Әллә бу берәр шаукым гынамы? Озак дәвам итәрме?***

Чынлап та, укучылар физикага ныграк тартыла. Илгә техник белгечләр җитми, техник юнәлештәге уку йортларында бюджет урыннары күбрәк бирелә башлады. Сәбәп тә шундадыр. Җәмгыять заказы үзгәрүгә карап, БДИ фәннәре дә үзгәреш кичерәдер, дип уйлыйм.

***Тормыш кредогыз нинди?***

Җилләр җиргә аударган саен, башны күтәреп алга атлау!

***Заман укытучысын ничек итеп күз алдына китерәсез?***

Беренче чиратта, чын укытучы ул - балаларны бөтен күңеле белән яратучы. Икенчедән, белемле һәм киң эрудицияле кеше. XXI гасыр укытучысы - ирекле, кыю белгеч, идеяләрен, көчен кызганмыйча, балаларны тормышка өйрәтүче.

***Мөслим гимназиясе укытучылары белән 7а сыйныфы укучысы Фәрхетдинова Айгөл сөйләште***

## БУШ ВАКЫТЫҢ БУШКА ҮТМӘСЕН

## Серле кунаклар (хикәя)

Барча тереклеккә хәерле иртә теләп, Кояш киң итеп елмайды, болытлар арасыннан Җиргә күз салды. Авыл читендәге чәчәккә күмелгән гүзәл йортның киң тәрәзәләреннән Кояш малайлары кереп, ятакта аунап ятучы кызның битеннән, чәчләреннән иркәләделәр. Кыз, уянасы килмичә, иркәләнеп киерелде, кояшның җылы, рәхәт нурларында коенды.

Иркә уянганда, Кояш шактый югары күтәрелгән иде инде. Бүлмәгә хуш исле җиләк исе таралган. Димәк, әниләре җиләктән кайтканнар. Аякларына йомшак башмакларын киеп, йокы бүлмәсеннән чыгып барганда, өстәл уртасында кукраеп утырган ак тартмага күзе төште. Ни өчен кабат өстәлгә менеп кунаклаган соң әле бу? Бу ак тартма дигәнебез, ишегалдында чирәм чүпләп, йөгереп йөргән каз-үрдәкләрнең “әнкәсе” иде. Үткән атнада гына, үз вазифаларын җиренә җиткереп үтәгәч, тәртипкә китереп, Иркә аны үзе келәткә чыгарып куйган иде, ләбаса. Кыз, кызыксынып, тартма капкачын күтәрде һәм “ah!” итте: тартма эчендә ниндидер серле кошчыкның чуп-чуар нәни генә йомыркалары!

*****

...Кояш, җир тирәли сәяхәтен дәвам итеп, Кушкаен үскән аланга тукталды. Нәрсә булган аланга? Танымаслык булып үзгәргән, гүя аланның күлмәген умырып төшергәннәр. Йомшак җилгә иркәләнеп, җай гына тирбәлеп утырган аллы-гөлле чәчәкләр дә, шул чәчәк таҗларына кунып чык тамчылары суыручы күбәләкләр дә күренми. Шәрәләнгән аланны үрсәләнеп кычкырган кош тавышы ярып узды. Чү! Нәрсә бу? Кушкаен янында тузып яткан кош каурыйларын күреп, Кояшның йөзе караңгыланды. Һәркөн аны каршылаучы, нәсел дәвамчыларының борын төрткәнен көтеп ояда утыручы ана кош канга баткан. Нарасыйларын саклап калырга теләгәндәй, сыңар канатын ояга салган кошның үле гәүдәсе ята. И кошкаем, Кушкаен төбенә оялаган булсаң, бәлки, исән дә калган булыр идең. Юк шул, кечкенәләрең көн дә кояш күрсен, җылыда булсын дип, агач күләгәсеннән качып, ачыклыкка оя кордың. Ә Кеше дигәннәрең табигать балаларын бер дә аямый шул, үзенә буйсынырырга теләп вата, кыра, җимерә. Менә бит син дә йомырка эченнән борын төртергә дә өлгермәгән кошчыкларыңны ятим калдырып китеп бардың.

*****

Тормыш дәвам итте. Һәр иртәдә Кояш барчасына: көчле-көчсезгә, явыз-яхшыга тигез итеп җылысын, яктысын өләште.

Бүген дә Кояш яшь киленнәрнең каккалап, суккалап кабартылган мендәрләре кебек болытларны куып таратты да үз биләмәләрен барларга чыкты. Кушкаен аланында бытбылдыкның сөенечле тавышын ишетеп хәйран калды. Әткә кошны чуар, мамык кебек йомшак йомгаклар сырып алганнар. Бу шатлык әткә кошка Иркәнең әти-әнисеннән бүләк иде.

*****

Теге көнне, көтүләрне озаткач, Иркәнең әтисе белән әнисе, көн суыгында җиләк җыеп кайтырга дип, аланга җиләккә килгәннәр иде. Аланның печәнен күптән түгел генә чаптырып киткәннәр икән. Җиләкне чиләккә түгел, тәлгәшкә генә җыя алдылар. Аланга килгәч, һәрвакыттагыча, икесе бергә үрелеп үскән гашыйк каеннарның хәлен белергә дип, бер-ике адым гына атладылар да җан тетрәндергеч күренешкә тап булып катып калдылар: яшәү өчен көрәшеп яткан кош һәм чуар нәни генә йомыркалар иде анда... Әнкә кошка берничек тә ярдәм итеп булмый, ә менә кошчыкларны коткарырга өмет бар. Шамил абзый әле суынып та өлгермәгән йомыркаларны түбәтәенә тутырды да күкрәгенә яшерде.

*****

... Көн кичкә авышты. Әткә кош кошчыкларын канат астына җыйнады. Кушкаен аланында бытбылдыклар тавышы тынмаячак, аның нәсел җепләре өзелмәгән, исән, яшиләр.

***Илүзә Кашапова,***
***8 нче а сыйныфы***

## Яшерелгән сүзләрне тап (13 сүз)

| | | | | | | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| К | И | Я | Ч | С | М | И | Т | Җ | О | К | Р | О | Л | К |
| А | Б | М | К | А | Р | И | Я | Ч | С | Ы | Й | Ш | О | Ы |
| Р | Җ | В | Ө | К | В | П | Г | Г | Т | Ш | Ө | Г | Т | Ш |
| * | О | А | А | П | Р | С | Р | О | Л | * | К | Н | Ш | * |
| К | П | Ф | Б | Ү | З | А | У | К | Е | Б | У | А | Ә | Я |
| Ы | А | Ы | У | Э | Ә | Л | А | В | Ч | А | Н | А | З | Ң |
| З | В | С | Р | Л | Э | К | Ү | И | Ю | Б | А | Е | Х | А |
| Ы | Ы | М | А | Б | Ң | Ы | Э | Җ | М | А | Р | И | Ү | * |
| А | У | Р | Н | Д | Ю | Н | У | Е | Н | Й | Н | О | Б | Е |
| И | Н | Э | Ә | З | Х | Ү | Г | Е | А | М | И | Т | Җ | Л |
| Ч | А | Ң | Г | Ы | Ы | В | П | Р | О | Т | А | У | Б | Ю |
| Й | Ө | У | К | Е | Н | Г | Ш | Ә | З | Х | Ү | Э | Д | Л |
| Й | Җ | Т | Ш | Ә | К | А | Р | * | Б | А | Б | А | Й | К |
| Ө | И | Е | О | Л | Д | Х | Ү | Э | Ң | Ш | Б | Ю | Ң | Э |
| У | Л | Н | Г | Т | И | М | Е | Р | А | Я | К | А | С | П |

ТЫЛСЫМ+
Гыйнвар , 2015 нче ел
***Мөслим гимназиясе укучылары газетасы***

**Баш мөхәррир:** Тимергалиева Э.В.
**Техник редактор:** Кадыйрова А.Р.
**Мөхәррир:** Исмәгыйлева Язилә
**Корректор:** Мухаметханова Айгөл,
**Корреспондентлар:** Мәгъдәнова Ләйсән, Фәрхетдинова Айгөл, Кашапова Илүзә
**Дизайнер:** Галиев Илназ

**Компьютерда җыючылар:** Гилемов Азат, Хәбибуллин Руслан
**Гамәлгә куючы:** Мөслим гимназиясе укучылар иҗат үзәге
**Адрес:** Мөслим, Кооператив урамы, 170а
**Электрон адрес:** tilsim.gimnazia@yandex.ru
**Сайт:** https://edu.tatar.ru/muslum/muslumgym